РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.10.2016 №1271-п

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын төзүче оешмаларга биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче зат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат булган Саба муниципаль районы милкендәге (җир кишәрлекләреннән тыш) Исемлекне раслау турында

«Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән, һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга тапшыру өчен билгеләнгән өченче зат хокукларыннан (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының (җир кишәрлекләреннән тыш) муниципаль мөлкәтен арендага бирү тәртибен (җир кишәрлекләреннән тыш) раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2016 елның 30 сентябрендәге 71 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы милкендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биләүгә һәм (яисә) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән өченче зат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) хокукларыннан азат булган муниципаль мөлкәт (җир кишәрлекләреннән тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар исемлеген (кушымтада бирелә) расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе А.М. Галиуллинга йөкләргә.

Саба муниципаль районының
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Р.М.Гасимов